СӨЙ ҒОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫҚНЫ, СӨЙ ХАЛЫҚНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫҢЫҢ ИЖТИМАҒЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №116 (7889) | 28 сентябрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

Семинар-киңәшмә үтте

25 сентябрь көнне район Советының кече залында колхоз-совхоз җитәкчеләре, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белгечләре катнашында семинар-киңәшмә үтте. Аны кереш сүз белән халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе Х. Х. МОРАДЫЙМОВ ачып җибәрде. Ул семинар-киңәшмәнең максатын ачыклап, алда торган кышлату чорына әзерлек буенча кичектергесез бурычларны билгеләде. Аннан соң авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең баш агрономы Н. М. МУСИН бүген хуҗалыкларда киләсе ел уңышы астына башкарыласы эшләргә басым ясады, чөгендер алу һәм аны дәүләткә сатуның торышын анализлады. Шул ук вакытта ул орлык хәзерләү—хуҗалыкара алмашу, булганнарны калибрлау һәм башкалар буенча башкарыласы эшләргә тукталды.

Семинар - киңәшмәнең практик өлеше Хафизов исемендәге «Россия» колхозлары, «Төрнәс» совхозында уҗым культуралары кырында көтүлекләр йөртү тәҗрибәсен караудан башланды. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе баш зоотехнигы А. А. БЕЛЯКОВ шуна бәйләп терлекчелек тармагында бүгенге торыш, малларны кышкы биналарга кайтару мәсьәләләренә тукталды, ел үзенчәлекләреннән чыгып тармак эшчәннәре алдында торган бурычларга тукталды. Аннан семинарда катнашучылар «Заветы Ильича» колхозында җәмәгать маллары өчен халыктан бәрәңге туплау тәҗрибәсен карадылар. Биредә ул 650 центнер әзерләнгән, тагын 300 центнер җыю мөмкинлеге бар әле. Авыл хуҗалыгы идарәсенең азык җитештерү буенча зоотехнигы Х. Х. ХАЛИТОВ фураж белән зур кытлык көтелгән быелгы кышлатуда бу төр азыкны мөмкин кадәр күбрәк тупларга кирәклегенә басым ясады, бу юнәлештә уңышлы эшләүче «Рассвет» совхозы, «Заря», «Правда» колхозларын үцай яктан билгеләп үтте. Аның чыгышында азык әзерләүнең торышына анализ белән бергә, булган азыкны хисапка алу, төгәл үлчәп куллану кирәклегенә дә басым ясалды.

Семинарда катнашучылар алдында техниканы кышкы саклауга кую, аңа таләләр турында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең баш инженеры М. В. ЗӘЙНУЛЛИН, «Гостехнадзор» инспекциясе начальнигы Р. С. САТТАРОВ иптәшләр чыгыш ясадылар. Шунда ук «Заветы Ильича» колхозының машина-трактор паркында техниканы кышкы саклауга куюны оештыру белән таныштылар.

Семинар-киңәшмәдә халык депутатларының Октябрь районы Советы рәисе Х. Х. Морадыймов йомгаклау сүзе белән чыкты.

Сыер савучы профессиясенең җиңел булмавы турында һәркем яхшы белә. Бигрәк тә бүгенге яшьләребез товарлыклы-сөтчелек фермаларына барудан өннәре алынып тора. Ә бит бер уйласаң, Миңлегөл Хәбибулловна Сафиуллина эшкә килгәндә, хезмәт шартлары күпкә авыррак иде. Көянтәләп терлекләр өчен «аш» ташыдылар, бина идәннәрен ышкып-ышкып юдылар. Ә терлек азыгын җилкәләренә салып бинага ташыган чаклары аз булдымыни? Ләкин ничек кенә булмасын, тормыш авырлыклары алдында югалып калмады сыер савучы Миңлегөл Хәбибулловна. Берүк вакытта өч бала тәрбиләп үстерде, гаиләсен карады. Аның иптәше Шәһит Хәмитович Фәсхетдинов та «Чирмешән» колхозында мактаулы механизаторлардан санала. Хуҗалыктагы бер эш тә аңардан читтә калмый. Кышкы чорга кергәч МТЗ-80 тракторы белән ул саламын да, урманын да ташый.

Рәсемдә сез «Чирмешән» колхозы сыер савучысы Миңлегөл Хәбибулловна Сафиуллинаны күрәсез.

„Дуслык"ны кем дус итә?

Сөйләшүгә чакырабыз: сез 1992 елда газетаны нинди итеп күрергә телисез?

Әле күптән түгел генә «Дуслык»ның 60 еллык юбилеен бөтен районыбыз белән зурлап билгеләп үттек. Район газетасы озын ижат юлы узды. Үзебезнең төбәктә яшәүче күпмеңле төрле милләт кешеләренең уй-фикерләрен, борчыган сорауларын тулырак яктырту өчен редакция коллективы көчен кызганмады. Коллектив бүген дә яңа ижат әзләнүләре белән яши, алга планнар кора. Газетаны кызыклырак, эчтәлекләрәк итү өчен тырыша. Ә һәрвакытта да моңа ирешәме-юкмы икәнлеген иң беренче сез—укучыларыбыз хөкем итәргә тиеш дип саныйбыз. Газетабызның якын киләчәктә нинди булачагы турындагы сүз дә сезнең артта кала. Һәм шушы сорауны без киң җәмәгатьчелек киңәшенә чыгарабыз: нинди материаллар сездә зур кызыксыну уята, э нинди диләр сезгә ошамый, сезне газетаның теле, язу стиле, материалларны бирү рәвеше, бизәлеше канәгатьләндерәме?

Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Без сезнең бу сөйләшүдә актив катнашуыгызны, конкрет тәкъдимнәрегезне, уй-фикерләрегез белән уртаклашуыгызны көтәбез.

Атнаның шимбә һәм якшәмбедән кала теләсә кайсы көнендә (редакция 8 дән 17 сәгатькә кадәр эшли) сез 2—18—67 номеры белән телефоннан шалтырата яисә фикерләрегезне безгә хат аша житкерә аласыз. Сездән кергән һәр сүз, һәр тәкъдим безнең эш планында чагылачак. Шулай бергәләшеп, киңәшләшеп эшләсәк кенә без газетабызны көн таләбенә жавап бирерлек итеп чыгара алырбыз дип уйлыйбыз.

Сездән хәбәрләр көтәбез!

Язылу әле дәвам итә

Хәзерге вакытта киң колач белән җәелеп киткән газета-журналларга язылу кампаниясе күп кешеләр алдында киң сайлау мөмкинлеге куйды. Беренчедән, басмаларның саны артты, эчтәлекләре төрләләнде. Икенчедән, монысы бигрәк тә мөһим, аларга язылу бәясенең «теш» үтмәслек югары булуы пенсия акчасына гына яшәүче өлкән буын вәкилләре һәм аз керемле гаиләләр өчен зур бәлага әйләнде.

Ләкин безнең «Дуслык» бу катлам кешеләр дә языла алырлык үткән елгы бәясен саклап калды. Шулай ук районыбыз тормышы, башкарылган эшләр газета битләрендә көзгедәге кебек чагыла бара. Бер үк вакытта безнең матбугат сүзе һәрвакыт хезмәт кешесен данлаучы, аларга югары житештерүчән эшләү өчен илһам бирүче булды.

Моны истә тотып, күп кенә авыл почта бүлекчәләре район газетасына язылу кампаниясен киң җәелдерде. Бу эшне төрле ысуллар—индивидуаль подписка, ведомость белән язылу һәм башка төрләрен кулланып, уңышлы гына эшләп киләләр. Алар—Сәләнгәш, Түбән Чаллы, Андреевка, Киекле, Гәйтән почта бүлекчәләре.

Исемлекне дәвам итәргә бик теләсәк тә, әлегә булмый шул. Күп хуҗалыклардагы язылу торышыннан күренгәнчә, авылдагы 5—7 йортның берсе генә безнең газетага язылуын берничек тә аңлатып булмый инде.

Бу авыл элемтә бүлекчәләрен санап торуны кирәк тапмыйбыз, чөнки һәркемнең үз эшен белеп, искәртүләрсез жиренә житкереп башкарырга тиешлеге ачык хакыйкать ич.

Хәзер авылда көзге эшләр йомгакланып бара. Вакытлы матбугатка язылу әле дәвам итә һәм бу эш өчен жаваплы иптәшләрнең калган вакытны нәтиҗәле файдаланып, үз бурычларын намуслы үтәп чыгарлар дип ышанып калабыз.

Начальник сайланды

26 сентябрь көнне торак ремонтлау һәм төзү участогында (УРСЖ) коллектив жыелышы булды. Анда Р. Р. Мәхмүтов шәхси гаризасы нигезендә начальник вазифасыннан азат ителде. Участок начальнигы итеп Григорий Иванович Шугаев сайланды.

Жыелышта «Татремстройбыт» тресты профсоюз комитеты рәисе Ә. И. Фәсхетдинов һәм халык депутатларының Октябрь район Советының оештыру бүлеге мөдире Ф. Ш. Галимов иптәшләр катнаштылар.

◇ Бер колхоз хәбәрләре

Көтүчеләр

Аларның иң алдынгылары өчәү бездә. Таналар көтүче Анатолий Сухов—шуларның берсе. Анатолий карамагында 100 баш тана исәпләнә. Көтүче үз эшенең бөтен нечкәлекләрен белеп, жиренә житкереп башкара. Ерак көтүлектә булганлыктан, аның өстеннән контроль дә юк диярлек. Әмма Анатолийга ул кирәкми дә: ул һәр эшне күңеленә ятканча, жаны кушканча эшләргә гадәтләнгән.

Симертүдәге малларны көтүчеләр Мөнир Әһлиуллович Нәбиуллин белән Наил Хәсәнгатович Кыямов та нәкъ шундыйлар. Мөнир Әһлиуллович 30 еллап шул хезмәттә инде. Малларның холык-фигылен, көтүне оештыру нечкәлекләрен аннан да яхшы белүче бөтен колхозда юктыр. Шуна ул көткән маллардан артым дә һәрчак югары—750 шәр грамнан да кимеми. Быел жәй терлекчеләр слетында ул районның алдынгы терлекчеләре исәбеннән аерым зурлау, бүләкләүгә лаек булды. Тәжрибәле остаз үзенә кулдаш итеп шулай ук эшчән һәм тырыш Наил Хәсәнгатович Кыямовны алды. Наил остазыннан күп нәрсәгә өйрәнеп буласын тиз аңлады, аның кебек үк жаваплылык белән эшли.

Булышырга да өлгерделәр

Илһам Хафизов житәкчелегендәге аренда звеносы турында әйтүебез. Хуҗалыкта чөгендер алуны ике сменада оештырдылар алар. Илһам үзе комбайннан чөгендерне кагатларга ташып торды. Сәлим Ханиев, Жәмил Хәлимов БМ-6 белән чөгендер яфрагын урдыруны бик тегәл алып бардылар, КС-6 комбайнында эшләүче Илһам Галимжанов, Таһир Хәлимовка бер дә тоткарлык тудырмадылар. Чөгендер ташуда эшләүче Юныс Мортазин, Хәким Нуретдинов, Хәниф Хафизов, Ринат Хафизов та эштә өзеклекләргә юл куймадылар. Шулай бердәм эшләү нәтиҗәсендә 100 гектарлы үз кырларында эшне беренче булып тәгәлләделәр. Участок 220 шәр центнер уңыш вәгъдә итә —моңа арендачылар шулай ук бик сөенделәр. Үзләрендә эш бетүгә, икенче звенога ярдәмгә ашыктылар Хафизов егетләре.

И. ХАНИЕВ.
«40 лет Победы» колхозы.

САУЛЫКХАНӘ

ҮЗ КЕШЕ

(ОЧЕРК)

«...Шул ук төндә Түбән Чаллыдан алкоголь белән агуланган Юрий Николаев авыр хәлдә участок больницасына китерелә. Шифаханәнең баш врачы Аркадий Клементьевның медицина персоналының тырышлыгы белән генә гомере сакланып калына».

Бу юллар «Дуслык»ның 17 сентябрь санында басылган «Тархун бизгәге» дигән мәкаләдән алынды. Тулаем язма эчкечелеккә багышланган, әмма милиция хезмәткәре И. Осипов, очраклы рәвештә булса да, доктор өчен хас моментны эләктереп алган. Кеше язмышы кыл өстендә чагында Аркадий Леонтьевич берни белән дә санашмый. Моны дәлилләп күпме факт китерергә мөмкин.

Менә тагын мисаллар. Норлатлы Иван Петровның аяклары хәрәкәтләнми башлагач иде. Әлеге больницаның неврология бүлегендә дәваланып кайтты һәм, кем әйтмешли, жимерттереп эшләп йөри. Киекле авылыннан Насыйх Мостафинны койкага кадәр күтәреп менгезәләр. Ул исә, блокада ясаганнан соң, үз аяклары белән йәреп чыгып китә. Операция ярдәмендә гомерләре саклап калынган авырулар күпме?!...

Аркадий Леонтьевичның чирек гасырга якын табиблык итү чорында андыйларны саный китсәң бер китап калынлык исемлек барлыкка килер иде. Һәм шунысы бар, аларның исәнлеге, савыгуы өчен күпме хезмәт куярга, тырышырга, образлы әйткәндә, көрәшергә туры килгән.

Хәер, доктор Клементьев диалектик материализмны, аның капма-каршылыкларның көрәшен егет чагыннан үзләштергән, шәхси тормыш мисалында ачык татыган кеше. Ул тормышны шунсыз күз алдына да китерми.

Гәйтәндә жидеелык мәктәпне тәмамлагач, Якушкинога йөреп укыган чорында ук ул үзе өчен гомерлек профессияне күңеленнән сайлап куйган инде: иң гуманлы, игелекле һөнәр иясе—доктор булачак. Урта мәктәпне бик яхшы билгеләренә тәмамлый, төгәл фәннәрне ныклап үзләштерә. Техник югары уку йортларының күбесенә бик ансат үтә алган булыр иде, әмма ул баштагы карарыннан чикми. 1960 нчы елда, ике еллык колхоз стажы туплагач, Казан медицина институтына юл тота. Дәвалау факультетына бер урынга ничә абитуриент имтихан тотканын һәркем белә—дистәгә житә. Оялчанлыгын жиңеп өлгермәгән авыл малайларын көтеп тормыйлар анда.

Конкурстан үтмәсә үтмәсен, күнелен биздерми Аркадий. Хәрби хезмәттән соң кабат шул ук институтка килә.

Табиб дипломы алып туган якка кайткач, 1969 елдан бирле хезмәт кенәгәсендә аның бер генә төрле язу: Иске Чаллы участок шифаханәсе баш врачы. Һәм монда да аны юлларына гөлләр сибеп каршы алмыйлар: ул ябылырга тиешле шифаханәгә жибәрелә. Яшь хирург тормышта шактый чирканчык алып өлгергән инде, югалып калмый, югары инстанцияләр алдында шифаханәне саклап калу көрәклеген күтәрә. Бу мәсәләдә ул үзенә фикердәшләрне тиз таба. Шуларның иң кодрәтлесе һәм «тешлесе» Синдряков исемендәге колхоз рәисе Ленин орденлы, заманында СССР Югары Советы депутаты булып торган мәрхүм Николай Леонтьевич Филиппов була. Дөресен әйтергә кирәк, ул якламаса, районда исеме дә жирле халыкка гына билгеле булган яшь доктор безнең бюрократик системаның бәтен броняларын тишеп үтә алмас иде. Мондый терәк булгач, каршы төшмиләр, әмма кул сузарга да ашыкмыйлар: яңа шифаханә бинасы салырга икән (искесе авария хәлендә, бу котылгысыз) киртә юк, тик средстволарны табу—инициаторлар эше. Николай Леонтьевич эш башларга беренчел средстволарны бүлә. Аннан бу врачлык участогына кергән башка хужалыклар да өлеш кертә.

Шифаханә төзү биш елга сузыла. Ул чорда баш докторга авырулар язмышы белән мәшәкатьләнергә генә түгел, төзелеш материаллары табу, объекттагы эшнең сыйфаты һәм шуларга бәйле башка күп проблемаларны да хәл итәргә туры килә. Профессиональ осталыгы белән бергә хужалык эшләрен оештыру сәләте дә ачыла.

Хәер, алда әйтелгәнчә, хәзер ул хәрәкәтсез яшәп белми дә. Төп корпус төзелгәч неврология бүлеген ачу мәшәкатьләре белән яшәп башлый. Анда ләм, су һәм башка препаратлар белән нерв авыруларыннан район халкы дәвалана. Хәзер шифасын әйтеп бетерә алмыйлар.

80 кеше эшләгән шифаханәнең көндәлек хужалык мәшәкатьләре үзе генә дә күпме вакыт ала. Аркадий Леонтьевич бу мәсьәләдә дә үзен чын, тулы мәгнәсендә хужа итеп тота белә. Һәр жирдә үрнәк тәртип, чисталык, санитария таләпләренең үтәлеше һәрчак аның күз уңында. Миңа, шифаханәләрнең төрле бүлегенә еш мөрәжәгать итүче һәм шул жәһәттән әйтү кирәк, медикларның төрлесен күргән кешегә, биредәге тәртипләр күңелгә нык уелып калды.

Иң беренчесе—дәваланучыга мөнәсәбәт. Баш врачтан алып санитаркага кадәр авыруга ихтирамлылык, игътибарлык. Беркайчан берсе авызыннан пик бер—дорфалык кая—зарлану сүзе ишетелсен. Һәркем үз вазифасын төгәл һәм тулы үти.

Болар барысы Клементьевның үзеннән, коллективта хезмәтне оештыра белүеннән килә.

...Шулай килеп чыкты ки, бу шифаханәгә эш сәгате башланудан күпкә алдан килдем. Кабул итү бүлмәләре бикле, икенче каттагы дәваланучылар торып кына килә иде әле. Дежур медицина работникларыннан кала берәү дә юк. Моннан әйтәсе килгәнем шул: башлап баш кеше үзе килде. Аннан башкалар. Бу очраклы хәл генә түгел: ул авыруларны карап чыгуны да алты көндә тәрле вакытта үткәрә. Хужалык эшләре белән китәсе булганда пациентлар йокыдан торган вакытка ук кереп житә.

Участок шифаханәсендә шәһәрдәге тәртипләрдән аерма шактый. Норлаттан килеп дәваланучылар (алар монда неврология бүлегендә курс узучылар һәм, моннан тыш, үзәк шифаханәдә урын житмәгәндә килеп стационарда ятучылар) моны аеруча сизәләр. Безне гажәпләндергәне сырхауны иза чиктерә торган озын-озын чиратлар юк. Әмма бу авыл медикларының эше аз дигән сүз түгел. Докторлар пациентны кабул да итә, стационарда да дәвалый. Участок зонасына кергән колхозларга профилактик тикшерүләргә дә даими чыгып торалар. Авыруларның өйләренә дә йөриләр. Шифаханә урнашкан Иске Чаллыга гына түгел, иң ерак авылга кадәр.

Авыл докторы өчен дә эш житәрлек, димәк. Шунысы да бар, алар арасында профессиональ бүленеш юк. Иске Чаллыда мәсәлән, өч врач эшли. Валентина Павловна, Клементьевның хатыны—терапевт, Юрий Николаевич Мальков—стоматолог. Әмма бу шартлы гына, һәркайсы башка белгечлек буенча да дәвалый. Аркадий Леонтьевичка вакыты белән хирург, рентгенолог, терапевт, невропатолог, лор врачы—кыскасы, нинди генә белгеч булырга туры килми. Һәм кеше ярдәмгә мохтаж вакытта вазифаны тикшереп тору мөмкинме соң?

Аркадий Леонтьевич—таләпчән кеше. Больница режимын бозучы булса аннан мәрхәмәт көтмәсен инде. Тормышта аның үз принциплары бар. Үз сәламәтлеге турында үзе кайгыртмаган кешегә рәхим, шәфкать көтәр урын юк. Биредә дәваланучы һәркеменең больница кәгазенә режимны ничек саклавы турында врач яза бара. Күп шифаханәләрдә моңа игътибар бирмиләр әле, минемчә, тәрбияви роле зур моның.

Доктор Клементьевның тормыш юлы белән кызыксынгач, үзем өчен тагын бер көтелмәгән яңалык ачтым.Ике дистә елдан артык сәламәтлек сагында торган, районның һәр почмагында исеме яхшы таныш, абруй казанган табибның бер ниндидер мактаулы исеме, профессиональ осталык билгесе дә юк икән. Дөрес, якын көннәрдә аңа сәламәтлекне оештыру буенча беренче категория белгеч исеме бирергә жыенулары мәгълүм булды, бусы бик әйбәт, ләкин ул районда оештыручыдан элек, шифалы куллы табиб буларак популяр ич. Неврология бүлегендә тәннәренә шифа, сихәт алган бик күп якташларыбызның да фикере бу, минемчә.

Моның белән мин аның сәламәтлекне оештыру өлкәсенә куйган хезмәтләрен һич киметергә теләмим. Тирә-яктан яшел чыршыларга күмелеп утырган шифаханәне салуга керткән шәхси өлеше генә дә халык күңелендә якты хәтирә булып сакланырлык һәм сокланып сөйләрлек хезмәт, аның тормыштагы эзе, үзеннән соң да каласы якты сукмагы. Хәер, бу лирик чигенешем өчен Аркадий Леонтьевичтан гафу үтенәм: сүз аны пенсиягә озату турында бармый, бинаның йөзләрчә елларга исәпләп салынуын гына билгеләп үтәсе килә. Аркадий Леонтьевич әле энергиясе, сәләте ташып торган, яшь чактагы кебек тормыш киртәләренә каршы яңа көрәшләргә әзер, һаман принципиаль һәм туры сүзле, ин мөһиме, шифаханәдә дәваланучылар өчен бик кирәкле, шифалы куллы кеше. Алар өчен ул—үз кеше.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.
Норлат шәһәре.

Алевтина Викторовна Макарова 1987 елдан бирле урман промышленносте хужалыгы ОРСында склад мөдире булып эшли. Ул үз вазифасын зур жаваплылык һәм төгәллек белән башкара, шуңа күрә хезмәттәшләре арасында да тиз арада абруй казанды.

Моңарчы Алевтина Викторовна ремонт-техник предприятиесенең төзелеш участогында гади эшче, йөк ташучы булып эшләгән иде. Кайда гына булмасын, сынатмады.

Рәсемдә: урман промышленносте хужалыгы ОРСының склад мөдире А. В. Макарова.

„Кайгыртучанлык“ программасы—хәрәкәттә

Элек-электән картлар турында кайгыртучанлык күрсәткән жәмгыять гуманлы саналган. Пенсионерларның социаль тәэмин ителешенең канәгатьләнмәслек булуы турында без хәзер генә ачыктан-ачык сөйли башладык. Үзебезнең яшәвебез, көн итүебез белән без шул өлкән буыннарга бурычлы. Һәм без аларга шул бурычны кайтарырга тиешбез. Шуңа күрә Берләшкән Милләтләр Оешмасының 1991 елның 1 октябрь көнен халыкара өлкән яшьтәге кешеләр көне дип игълан итүе һич очраклы түгел. Аның максаты—халыкның картаюына, өлкәнләр тормыш-көнкүреш кыенлыкларына игътибар юнәлдерү, мохтажларга ярдәм күрсәтү, ялгызларга булышу.

Без 1 октябрьгә кадәр калган вакыт эчендә хатын-кызлар советларын—хезмәт коллективлары вәкилләре, профсоюз комитетлары, укучылар белән берлектә—өлкән буын кешеләре янында булып чыгарлар, аларга жылы игътибар бирерләр, хужалык проблемаларын хәл итүдә булышырлар дип ышанабыз.

Катлаулы тормыш юлы үткән кешеләргә бүген торак алу, бушлай йөрү һәм алар өчен каралган башка өстәмәләрне гамәлгә ашыру гына житми. Алар өчен яшьләрнең ветераннарга игътибары һәм хөрмәте мөһим. Безне күптән түгел лексиоңыбызда бик сирәк яңгыраган «Игелеклелек»нең тормышка кинрәк керә баруы сөендерә. Без үзебезгә якын кешеләргә генә түгел, гомумән өлкән буын вәкилләренә игътибарлылык турында сүз алып барабыз. «Кайгыртучанлык» программасы рамкаларында, «Россия тол хатыннары» акциясе барышында хатын-кызлар хәрәкәте активистлары, социаль тәэминат работниклары, тимурчылар өлкән буыннар янында күп булдылар инде. Аларның ихтыяжларын белешеп хезмәт коллективларына, жәмәгатьчелеккә бу категория кешеләренә ярдәм күрсәтүне үтенеп мөрәжәгать иттеләр. Һәм бу эшнең башлангычы гына. Әйбит безнең ветераннарның: «Ничек яшисең?» дигән сорауга горурлык белән: «Бик әйбәт» диярлек көннәргә яшәвен бик телисе килә. Материаль як белән бергә жылы караш, игътибар тоеп аларның елмаюын бик күрәсе килә.

Ветераннар белән очрашканда, әйдәгез, аларга һәрчак елмаю бүләк итик, игътибар бирик.

Хатын-кызларның район советы.

Разия Кыям кызы Могыйнова пенсия яшендә инде. Ә кече яшьтән хезмәткә өйрәнеп үскән кешенең күллары тынгы беләме соң? Ул ничәмә-ничә еллар буе чөгендер үстерде, сыерлар сауды, бозаулар карады, кирпеч заводында да эшләде. Һәм кайда гына хезмәт куйса да үзен карусыз, тырыш, тыйнак ип-тәш итеп танытты. Разия Кыямовна әле бүген дә кул кушырып өйдә утырмый. Кулыннан килгәнчә колхоз эшләрендә катнаша.

Рәсемдә: «Татарстан» колхозы колхозчысы Р. Могыйнова.

С. Казакова фотосы.

ГАЗЕТАДА БАСЫЛМАСА ДА...

Редакциягә иске заправка артыннан бирелгән дача участогы хужаларыннан хат килде. «Хатта: «Әлеге участокларга эре агачлар утыртырга, өй житештерергә рәхсәт ителми дигән хәбәр йөри. Ул участокларда көч түгәрә кирәкме икән соң? Акча түләнде, тик тирәсе тотылаган, сакчы куелмаган әле. Жаваплы кешеләр рәсми жавапны газета аша бирсеннәр иде»,—дип язалар бер төркем ширкәтчеләр.

Хат тикшереп жавап бирү өчен Норлат шәһәр Советы башкарма комитеты председателе иптәш М. М. Фәрраховка жибәрелгән иде. Андан түбәндәге жавап килде:

«Әлеге участок даими файдалану өчен бүлеп бирелгән. Хужалар анда бакча өйләре төзи һәм бакчачылык жәмгыяте уставы нигезендә агачлар утырта алалар.

Ә инде участокның тирәсен тоту, су үткәрү, сакчы кую кебек мәсьәләләр белән әлеге бакчачылык жәмгыяте рәисенә мөрәжәгать итәргә мөмкин.

Халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе

М. ФӘРРАХОВ».

• *Мең дә бер шөгыль*

ЕГЕТ БУЛСА, ШУНДЫЙ БУЛСЫН...

Мәдәният йортында, хатын-кызлар көненә багышлап, авыл яшьләре эстрада концерты бирә.

Концерт шундый итеп әзерләнгән, башкарылган һәрбер номер бер-берсен тулыландырып, бер-берсенә бәйләнеп бара. Музыкантлар һәр номерга үзенчәлекле музыкаль аһәң-(яңгыраш) биреп, аны төсләр гаммасы белән бизәп торалар.

Көтмәгәндә сәхнә төрле төс алып, сихри балкышлар нурында, дәртле музыка астында кала. Алып баручы сәхнәгә жәймә жәүп, өстенә пыяла, шешә ватыклары сибә, кадаклары өскә каратып кадакланган такта щитны сәхнә уртасына чыгарып куя.

Халык, бу ни булыр тагы диеп гажәпләнергә өлгермәгән, сәхнәгә яланаяклы авыл егете йөгереп чыга һәм барабаннарның шомлы кагуы көнә пыяла ватыклары өстендә бөтереленеп бии башлый. Ул да түгел, шул пыялалар өстендә ятып ауный, аркасы белән төрле хәркәтләр ясый, кадаклы щитка сикереп менеп, табаннары белән баса, аркасы белән шул кадакларга сузылып ята, өстенә үзе кебек үк авырлыктагы бер егетне менгереп бастыра.

Зал бер мизгел тагын умарта күчедәй гөжләп ала—алып баручы сәхнәгә ялтырап торган, хәнжәр сыман зур, үткен пычак алып чыга. Тамашачылардан пычакның чынлыгын, үткенлеген исбатлатып, пычакны сабыннан тотып, очлы ягын идәнгә каратып, егетнең корсагына турылап ыргытты, пычак тимергә бәрелгәндәй, корсактан шуып идәнгә тәгәрәде, тагын, тагын— берничә мәртәбә шул хәрәкәтләр кабатланды. Зал ах итте, ә егет, берни булмагандай, песидәй сикереп аякка бастты, залга баш иде. Мондый тамашаны циркларда гына карап күнеккән халык бермәл өнсез торганнан соң, егетне алкышларга күмде.

Ә сәхнәдә бернинди тылсымга да ия булмаган, фәкать үз тырышлыгы, спортка үлеп гашыйк булуы аркасында төрле мажаралар тудыра алуга ирешкән гади авыл егете Фәрит Шәйхетдинов басып тора. Бу концертны оештыруда, куюда да аның өлеше зур, башлап йөрүчеләрнең берсе иде. Башкалардан берни белән дә аерылып тормаган Фәрит мәктәптә укыганда ук спорт белән даими шөгыльләнә, урта мәктәпне тәмамлагач, кем булыйм, кая барыйм диеп уйлап та тормыча, Әлмәт физкультура техникумының физкультура укытучылары әзерли торган бүлегенә укырга керә.

Бер ел укыганнан соң, армия сафларында хезмәт итү, хезмәтнең дә ил чигендә—Ерак Көнчыгышта (Бикин шәһәре) булуы, үзенең башта спортротага әлегүе Фәритнең характерын, ихтыярын ныгыта, чыныктыра гына. Берничә ай хезмәт итүгә, техник бүлек командиры булып житешә. Дәүләт чигендә ике чик бозучыны тотуда актив катнашып, китүенә 8 ай дигәндә, туган авылына отпускага кайтып төшә.

Мондый бәхет күпләрнең төшенә дә керми бит, бик сирәк егетләргә генә насыйп була. Армиядә аның тревога группасында хезмәт итүе генә дә ныклы ихтыяр көчле, чыдам, житез булуы турында сөйли.

Армия сафларыннан кайтып укуын бетергәннән соң, 1983 елдан бирле Фәрит хужалыкта спорт методисты булып эшләде, мәктәптә төрле секцияләр житәкләде. Биредә ул житәкләгән секцияләр иң актив, иң кызыклы шөгыль буларак аерылып тордылар. Көрәшчеләр группасына, мәсәлән, IV—VIII класс малайлары йөри, дзюдо белән шөгыльләнә. Карап торсаң, аларның житезлекләренә, ныклыкларына хәйран кала торган. Һәрберсе, нәкъ песи баласы кебек, ничек кенә хәрәкәтләнсәләр дә аякларында басып кала белә-ләр, бөтерчек кебек «дошманнарыннан» саклана-лар. Үткән ел Әлмәт шәһәрендә уздырылган Бөтенсоюз турнирында катнашып, 35 команда арасында малайлар бишенче урынны яуладылар. Секциягә йөрүчеләрнең популярлыгы зур. Районда көрәш төрләрен, алымнарын күрсәтү буенча оештырылган турда да аларны яратып карадылар.

Фәрит житәкләгән баскетболчы кызлар командасы да тирә-як авыллар командалары белән очрашып, ярышып, призлы урыннарны яулыйлар.

Ә инде яшь туристлар түгәрәгенә килгәндә, биредә тагы да кызыклы чаралар оештырылды. Фәрит I һәм II категорияле туристик маршрут буйлап, сәяхәт итеп, ерак Казахстан чүлләрен-далаларын инләгән кеше, туризмга чын күңелдән гашыйк. Шуңа балалар белән һич иренмичә, яратып шөгыльләнә. Туристлар группасы белән Кондырча елгасы башланган урынга сәяхәт кылып, район туристлар ярышында катнашып, беренче урынга чыктылар. Республика ярышында алар 9 нчы урынга лаек булдылар. Ә шулай да балаларны иң сокландырганы, жәлеп иткәне—Фәритнең гажәеп ихтыяр көченә нигезләнгән сәләте, әлбәттә. Әмма ул күктән килеп төшмәгән, даими, өзлексез күнегүләр нәтижәсендә нык-ыган сәләт. Аларны Фәрит үзе генә белә. Ватык пыяла өстендә биерлек хәлгә килгәнче, башта байтак вакыт Кузнецов ипликаторында йөргән өйрәнә ул. Пыяла ватыкларында да тән жәрәхәте—кисүләр ала. Аутотренировка белән даими шөгыльләнеп, нерв системасын тынычландыру, канның микроциркуляциясен яхшырту, авыртуны тоймау сәләтенә ирешә, махсус гимнастика алымнарын үзләштерә: тәннең тыгызлашуына, тәнгә пычак кадалмас хәлгә житүен, үз-үзенең бәйсезлегенә ирешү, ике ел дигәндә халык алдына курыкмыйча чыгыш ясау бу зур нәрсә! Бүгенге көндә Фәрит бу өлкәдә инде үзе остаз, аның шәкертләре дә бар. Хәер, Фәрит күпьяклы мавыгуы белән ме, һәрчак яшьләрне үз янына тартып тора. Оештыру сәләтен ходай үзе биргән бугай ана. Әнә, былтыр яшьләр үз көчләре белән өмәләр ясап, дискотека мәйданчыгы ясадылар, узган жәй буе жыр, музыка, яшьләр тавышы тынмады. Концерт-спектакльләр куюда да Фәрит башлап йөрде. Кичләрен берничә группа белән дәвалау гимнастикасы үткәрде. Ләкин...

Такташ әйтмешли, эх, шул ләкине булмасын иде! Авылда аның янып йөрүен, һәртөрле шөгылен бала-чага уены итеп караучылар табылды. Фәритнең үзен төрле хужалык йомышларына тарта башладылар. Ә безнең хыялдан ерак ярлы тормышыбызда мондый вак-төяк эшләр бетеп тормады. Шулай итеп, хезмәте дәрәжәсезгә куелган Фәритнең дә рухы төшенкелеккә бирелгән минутлары ешайды. Ә бит иң мөһиме—Фәрит кебекләрнең күңелләре катып, адымнары сүлпәгләнеп, жаннарына битарафлык иңә башламасын иде. Бусы бит иң куркынычы. Битараф кешегә башлаган эшен, авылын ташлап китү берни тормый, ә лидерын, оештыручысын югалтса, яшьләр дә сүнәләр. Әнә быел бию мәйданчыгында музыка ишетелмәде, спорт залында тынлык булды. Болай да эш өчен генә яратылган авыл халкының ял итү, рухи азык алу мөмкинлеге менә-менә югалырга торганда...

Шөкер, Фәриткә бер дигән кулай эш табылды— урта мәктәптә балаларга физик тәрбия бирү укытучысы булып эшли башлады. Үзе яраткан спорт, балалар дөньясына чуму Фәриткә яңа канатлар куйгандай булды: ул яңа мәшәкатьләр белән чаба, яңа идеялар белән яна. Без әле аның нәтижәсен күрербез. Югары Норлат авылы егете Фәрит Шәйхетдинов үз дигәненә ирешә торган егет.

Ф. МӨХӘММӘТОВА.

? СОРАГЫЗ — ЖАВАП БИРӘБЕЗ

«Кадерле редакция! Жир алу өчен кем белән килешү төзергә? Аларның күләме ничек билгеләнә? Фермерлыкны юридик нигезләү ничек алып барыла? Шул сорауларны ачыклаучы булыгыз иде.

Рәис ГАНИЕВ.

Кизләү авылы».

Бу сорауларга жавап бирү йөзеннән, район Советының жир реформасы, жир ресурслары буенча комитеты рәисе Р. Х. Хәсәнов безгә крестьян (фермер) хужалыкларын алып бару өчен жир участоклары бирү тәртибе белән таныштырды. Рәис һәм аның кебек кызыксынучылар өчен без аны газетада да бирергә булдык.

Колхоз, дәүләт авыл хужалыгы предприятиеләре членнары иң элек колхоз идарәсенә, авыл хужалыгы предприятиеләре администрациясенә алар составыннан чыгуны һәм крестьян (фермер) хужалыгы алып бару өчен жир участогы бүлүне сорап гариза яздылар.

Әлеге участок бу административ районда авыл хужалыгы хезмәткәрләренә (колхоз-совхозда яшәүчеләр, аларга хезмәт күрсәтүчеләрне кертеп) туры килгән уртача жир өлешеннән чыгып билгеләнә.

Колхоз идарәсе, авыл хужалыгы предприятиесе администрациясе жир участогын сайлау һәм аның чикләрен билгеләү өчен халык депутатларының авыл Советы, жир комиссиясе члены, кирәк булган очракта жир ресурслары һәм жир реформасы буенча шәһәр (район) белгечләре катнашында комиссия төзи.

Жир участогын сайлау материаллары колхоз идарәсе беркетмәсе яки авыл хужалыгы предприятиеләре администрациясе приказы нигезендә рәсмиләштерелә, авыл Советы карарына тапшырыла.

Авыл (поселок) Советы жир участогы бирү турында карар кабул итә һәм крестьян хужалыгы башлыгы гаризасы, башка документлар белән бергә аны халык депутатларының район (шәһәр) Советына жир участогын тапшыру турындагы карарны өстә расларга юллый. Колхоз-совхоздан чыгарга теләүчеләргә инде конкрет жир участогын бирүгә карыны төшсәләр, район (шәһәр) Советы мөстәкыйль рәвештә 1 ай эчендә жир участогы бүлеп бирә.

Колхоз яки башка авыл хужалыгы предприятиеләре члены булмаган, ләкин жир алырга теләгән гражданнар район Советына запастагы жир участогы хисабына жир бирүне сорап мөрәжәгать итәләр.

Район Советы гражданнарга гомергә файдалану өчен, яки арендага жир бирү яки алу мәсьәләсен хәл итә, крестьян хужалыгын терки һәм бу хакта хәбәрне 5 көн эчендә гражданнарга житкерә.

Жир участогының чикләре билгеләнгәч, халык депутатларының район (шәһәр) Советы жирдән файдаланырга хокук бирә торган Дәүләт акты тапшыра.

Жир участогын арендага биргәндә, халык депутатлары Советы крестьян хужалыгы башлыгы белән килешү төзи. Ул Татарстан ССР хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча төзелә, жирне тапшыру турында акт аның состав өлеше булып тора. Актта участок мәйданы, аның урыны, сыйфат характеристикасы, культуратехник торышы һәм экономик торышы, экономик бәя күрсәткечләре күрсәтелә. Актта арендага алына торган жирнең планы өстәлә.

Крестьян хужалыгы житкәчесе беренче 5 елда льгота нигезендә бернинди налог түләми.

Банкта үз счетын ачуга килгәндә, ул болайрак башкарыла. Колхоз идарәсе карары һәм авыл Советы представлениесе нигезендә жир бүлеп бирү турында район Советы сессиясе яки президиумы карары кабул ителә. Шуңа нигезләнеп, участокның чикләре билгеләнә, дәүләт акты бирелә. Район Советы карары һәм дәүләт акты нигезендә жир хужасы жирле банк бүлекчәсенә бара һәм үз счетын ача ала. Аннан хужалыгын нигытырга теләсә, республиканың крестьян хужалыклары ассоциясенә мөрәжәгать итеп, кирәкле техника, инвентарь алуга чиратка баса, ссуда ала.

Матбугат сүзен—һәр йортка!

Берничә төрле газета алдыруыма карамастан, беренче булып кулыма үзебезнең «Дуслык»ны алам. Якташларымның эшләре, тормыш хәлләре, үзләрен борчыган мәсьәләләр турындагы язмаларга газетада һәрвакыт күп урын бирелә. Бер төбәктә яшәгәнлектән, алар бер газета укучыны да битараф калдырмыйлар дип уйлыйм.

Хезмәтем буенча турыдан-туры бу эшкә мөнәсәбәтем булганга, матбугат сүзен һәр гаиләгә житкерергә тырышам. Газета журналларга язылу кампаниясе башлану белән, үзебезнең почта бүлекчәсендә эшне шул максаттан чыгып оештырдык. Көзге кызу эш вакытында колхозчыларны эштән аермас өчен, хат ташучылар аларның өйләренә кереп, язып йөриләр. Ахырдан шуныңнигезендә колхоз бухгалтериясе безгә акча күчерә. Теләгән кеше турыдан-туры почта бүлекчәсендә дә языла ала. Бу уңайдан безнең хат ташучыларыбызның да тырыш хезмәте мактауга лаек. Менә Наилә Нуруллинаны алыйк. Ул үзенә билгеләнгән Үрнәк поселогында вакытлы матбугатка язылу кампаниясе башлану белән эшкә кереште һәм аны уңышлы дәвам итә.

Гомумән, Наилә турында үз һөнәренә бирелгән, эшен яратып һәм жиренә житкереп башкара диясе килә.

Бу сүзләр шулай ук Киекле хат ташучылары Флюра Заһитова һәм Зөлия Сөнгатуллинага да бик туры килә. Алар да бүгенге көнгә 5 меңлык газета-журналга язды ру эшен башкардылар.

Мин үзем дә почта бүлеген житәкләгәнче 13 ел хат ташучы булып эшләдем. Шуңа күрә анлашып, тату, бердәм булып эшлибез. Күрсәткечләребез дә өйбәт, планнарны елныц-елында үтәп барабыз. 1992 елга вакытлы матбугатка язылу әле дәвам итә. Димәк, безгә әле тынычланырга иртә, газета-журналларны һәр йортта алдырып укуга ирешү мөһим, чөнки хәзерге тормыш шуны таләп итә.

Саимә МИНЕКАЕВА,
Киекле элемтә бүлекчәсе начальнигы.

Киекле авылында яшәүче кадерле әниебез Гөлсирә Нургали кызы СӨНГАТУЛЛИНАны 50 яше тулу белән котлыйбыз! Аңа нык сәламәтлек, шатлык, бәхет, тынычлык телибез.

КЫЗЛАРЫ, УЛЛАРЫ, КИЯҮЛӘРЕ, КИЛЕНЕ, ОНЫКЛАРЫ.

x x x

Зирекле авылында яшәүче кадерле әтиебез Нәбиулла, әниебез Зәйтүнә Мотыйгуллиналарга тиздән 65 яшь һәм бергә гомер итүләренә 40 ел тула. Без аларны чын йөрәктән котлыйбыз, озын гомер, ак бәхетләр телибез.

УЛЛАРЫ ИЛГИЗ, КИЛЕННӘРЕ АЙНУР ҺӘМ ОНЫКЛАРЫ.

■ *Журналист блокнотыннан*

Җылы сүз—җан азыгы

Бибисара апа мине күздән югалганчы озатып калды. Үзе авыз эченнән генә нидер сөйләнә иде. Бары аныц:

—Ходай игелек бирсен үзенә, жылы сүзләрен дә күңелгә якын булдылар, ичмаса, —дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Әйе, кешегә күп кирәкми. Мин Бикуле авылында булганда Бибисара апаныц тормыш-көнкүреше белән генә кызыксынырга теләгән идем. Ә ничек килеп чыкты. Бер уч тутырып аца алтын акча бирделәрме, яки гарип улын терелтерлек сүз әйтә алдыммы, шатлыгы йөзенә үк бәреп чыкты Бибисара апаныц.

Ә бит гади колхозчы хатын, хәзер инде пенсионер Бибисара апа чын бәхет сезләрнец берсе. Колхоз саламын өйгәндә кибән башынан егылып төшеп ире Таһиржан үлә. Тугыз баласы белән берүзе торып кала ул. Житмәсә, төпчеге тумыштан йөри алмый: «Ник мина гына шундый кайгы-хәсрәтләр килә соң!», дип башын бәрә-бәрә елаган чаклары аз булмый аныц. Ярый әле үзен-үзе кулга ала алды: кисендерде, ашатты, карады балаларын, кеше алдында ким-хур булмасыннар дип тырышты. Хәзер әнә барысы да үсеп житеп үз гаиләләрен кордылар, тик менә төпчек улы Минсәлих. Карый да, йөрәк бәгъре өзелеп төшәрдәй була ана кешенец. Ни әйтсәң дә, үзе барында әле баланы кайгыртучы булыр, аннан кем карар?.. Бигрәк матур бала иде бит кечкенә чагында үзе. Күрше балалары зәңгәр күзле малайны карар өчен бишек тирәли тезелеп баса торганнар иде. Кем белгән бит аныц тумыштан гарип булганын, ул чагында берәүнец дә башына килмәде шул. Ә бала туганда травма алган, аннан рахит, балалар церебраль параличы. Авыру тарихына врачлар шулай дип язган. Хәзер улына 20 яшь, 60 яшьлек Бибисара апа аны урамга үзе күтәреп чыга, күтәреп алып керә.

Инвалид егетне мин урындыкка утырып торган килеш күрдем. Үзе оялчан. Үз халәтеннән бик тә уңайсызлана булса кирәк. Янына мыж килеп көтүләре белән чебеннәр ябырылалар. Их, дөнья! Шуларны куарлык та рәтец булмагач..

Минсәлих бөтенләй дә укый-яза белми икән. Моныц әчен әниләренә үпкәләде.

—Ичмасам, газета укыштырып утырыр идем,—ди ул. Ә Бибисара апа исә башка карашта: «Кем һәр көнне килеп аны укытып йөрсен!».

Инвалидларныц төрләре—кул, аягы хәрәкәтләнүчеләре бар. Ләкин Минсәлихныц хәле күпкә авыр. Ул кулларын хәрәкәтләндереп яза да, шахмат-шашка да уйный, үзе ашый да алмый. Газета-журналлар укымый. Карыйсыц да, күңелдән уйлап куясыц: «Нигә шундый булып туды соң әле ул? Нигә гомер буена интегергә тиеш?!

Минсәлихныц машинага утырып йөрисе килә. Абыйсыннан, аныц шикелле инвалидларга йөрү өчен машина бирелә дигән сүзләрне ишеткәннән бирле күңеленә тынычлык таба алмый. Югыйсә, аз гына булса да транспортка утырып йөри алса, башына мондый уйлар килер идеме икән. Терелүенә бөтенләй өметләнми анысы, ә машина? Шуны юнәтүдә булышсалар, нинди бәхетле булыр иде!

Бибисара апа үзе мондый зур хыяллар турында уйламый.

—Хет инвалид коляскасы булсын иде. Элек 30 сумга берәүдән сатып алган идек тә, жимерек, көпчәкләре йөрми,—ди ул.

Нәрсә диясец инде. Хәзерге заманда бу әйберләрне юнәлтү түгел, егетне хәтта өметләндерү дә мөмкин түгел. Бары жылы сүзләр генә әйтергә кала. Ни әйтсәц дә—жылы сүз—жан азыгы бит. Кем белә, бәлки чыннан да Әбделвәлиевнец хәленә керүчеләр дә табылыр.

Г. РӘХИМОВА.

01 хәбәр итә

1991 елныц 9 сентябреннән 23 енә кадәр районда 6 янгын очрагы булды.

11 сентябрьдә Норлат шәһәренец Мир урамында янгын чыкты. Нәтиҗәдә М. А. Кончевныц беседкасы янып китте. Чөнки хужа анда радиоалгычны кабызып калдырган булган.

13 сентябрьдә Ключи селогында Х. Ф. Нуриевлар хужалыгында янгын чыкты һәм аларныц абзаркуралары янды. Бу факт буенча тикшерү алып барыла.

16 сентябрьдә Норлат шәһәренец Гоголь урамы 16 йортында З. Г. Камалованыц абзарлары янды. Янгын саксыз тәмәке тартудан чыккан.

17 сентябрьдә Норлат шәһәре Островский урамы 41 нче йортта яшәүче В. Р. Филиппов үзенец йортына ут төртә һәм үзе дә янгында һәлак була.

21 сентябрьдә электр приборларыныц төзексезлеге Норлат шәһәре Бауман урамында яшәүче Н. Н. Уламасовлар хужалыгында янгын чыгуга сәбәпче булды.

22 сентябрь көнне Норлат шәһәре «60 лет Октября» урамы 9 йортта яшәүче Б. Н. Яницкий абзарында электр үткәргечне тоташтырган килеш калдырудан ут чыкты.

Алда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, янгынларга саксызлык һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәмәү сәбәпче.

А. АЮПОВ,
ОГПН инспекторы.

ЖИЛӘК-ЖИМЕШНЕ ШИКӘРСЕЗ НИЧЕК САКЛАРГА

Карлыган, крыжовник, мүк жиләге, кара милән һәм башка жиләкләрне яңа уңышка кадәр шикәрсез дә сакларга була. Моныц өчен өч литрлы банкаларга юылган жиләкләрне тыгызлап тутырасыц да, өстенә кайнар су коеп, 25—30 минут стерильләштереп аласыц, һәм калай капкач белән борып-каплап куясыц. Соцыннан шикәр комы кушып файдаланырга бик уңайлы була.

Я ходаем, табигать бу агачны ни өчен шулай гарипләде икән?

С. Майстер фотосы.

ГӨМБӘНЕ МАРИНАДЛАУ

Быел гөмбә күп. Маринадлау өчен вак, кортсыз гөмбә эйбәт. Юылган гөмбәләрне сапларыннан аерып, тозлы суга салып пешерәләр. 15—20 минут кайнаткач, суын түгеп, салкын су белән юалар. 1 кг. гөмбәгә стакан ярым исәбеннән су, 1 кашык аш серкәсе, чәй калагы белән тоз, 1 аш кашыгы шикәр комы, 50 гр темләткеч үләннәр, 10 гр сарымсак салып маринад ясарга. Юылган гөмбәләрне маринадка салып тагы бер сәгать кайнатасы һәм 15 минут парда тоткан чиста пыяла банкаларга тутырып, өстенә көнбагыш маесалырга кирәк. Инде банкаларны пергамент кәгазь каплап, салкын урынга куясы гына кала.

Мөхәррир урынбасары Р. З. АЙЗАТУЛЛИН.

Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.
Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәржемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, жаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА жыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәржемә ителә.

«Дуслык» газетасы ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.